## КЕРЕШ СҮЗ

Гадәттә, әдипләр үзләренең иҗат чишмәсен Габдулла Тукайның бөек шәхесенә һәм иҗатына бәйләп карыйлар, аннан илһам алдым, диләр.

Мин исә алай дип әйтә алмыйм. Шулай да мине милли әдәбиятыбыз һәм сәнгатебезгә тартучы шәхесләр барысы да Габдулла исемле иделәр…

Татар дәүләт академия театрының баш режиссёры Габдулла абый Йосыпов безгә, театр училищесы шәкертләренә, актёрлык осталыгыннан дәресләр бирде. Драматургия тарихы һәм классик язучыларыбыз белән якыннан торып таныштырырга тырышты. Татарстанның атказанган артисты Габдулла абый Фәтхуллин исә сүз осталыгына өйрәтте. Казан тамашачыларыннан даими рәвештә алкышлар яулаган Габдулла Шамуков та, комедия артисты буларак, сәхнә серләренә төшендерде, үзенең юмористик әсәрләрен укыды. Аның мәсәлләре гаять кызыклы һәм көтелмәгән чишелешләр белән тәмамланучан. Шундый осталыкка ия булган язучыны бөек мәсәлче И. Крыловка охшата идек без.

Кызганыч, матди сәбәпләр аркасында миңа театр училищесын тәмамларга насыйп булмады. Әмма дә ләкин югарыда телгә алынган талант ияләре гап-гади авыл малае тормышына җитди үзгәрешләр кертергә өлгергән иделәр. Әдәбият-сәнгать, мәдәният белән якыннан торып таныша башлагач, кулыма каләм алдым. Ул арада заводта эшли башлап, техника белән танышып өлгердем. Ниһаять, очучы профессиясен дә үзләштерергә җай чыкты. Шул рәвешле, минем үз темам барлыкка килде.

Заводта туган телемнән читләшеп бара идем бугай. Әмма Габдулла абыйлардан күпмедер дәрәҗәдә отып

калган лөгать, аң-белем мине милли мәдәниятебез, бигрәк тә телебезгә карата хөрмәт, аны ихтирам итәргә һәм чын күңелдән яратуга этәрде. Нәтиҗәдә мин, әдәби телебезне үзләштереп кенә калмыйча, иҗат дөньясына ук аяк бастым. Моны саф татар телендә чыгарган әдәби әсәрләрем генә түгел, шул өлкәдә алган «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемем дә раслый дип уйлыйм.

*Ошбу китабымны газизләрем әнием һәм әтиемә, барча туганнарыма, авылдашларыма багышлыйм.*

## Йортлары яңа булса да, минем авылым борынгы

Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,
Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем.

*Габдулла Тукай*

Бу шигъри юлларны мин күңелемдә еш кабатлыйм. Туган авылым Кәшәдән чыгып киткәнгә инде шактый еллар узса да, авылыбызның олы җанлы хезмәт сөючән кешеләре, сокланып туймаслык гүзәл табигате һаман да минем күз алдымда, күңел түремдә. Бу хыялда гына түгел. Чирек гасырдан артык Казанда яшәп ятсам да, һөнәрем очучы булгач, миңа туган якларга еш кайтып йөрергә туры килә иде. Чөнки авылым үзем оча торган һава трассасы астында ук кала. Мин аны картадан карамыйча да таныйм. Туган-үскән җирләрнең үз төсе, үз яме бар бит. Самолётта очып узганда, яшьлек хатирәләрем, җанга гаҗәеп бер җылылык, рәхәтлек өстәп, тирән дулкынландыра, мине яңадан балачагыма алып кайта. Үзебез торган урам, янәшәдә генә көмеш сулы инеш буйлары, яшел хәтфә түшәлгән болын-тугайлары, туган як табигатенең фәкать үзенә генә хас булган башка бик күп төрле җанга якын күренешләре мине һәрчак әнә шулай куандырып каршы алалар да күңелләрне сагышлы хисләргә төреп озатып калалар.

Олыгая барган саен, кеше үзенең яшьлегенә ешрак кайта, диләр. Мин дә хәзер шундыйрак тойгылар кичерәм кебек. Бигрәк тә очыш вакытында ачык тоя һәм хыялымда гына булса да шул халәттә күпмедер яшәп кала идем.

Тиз йөрешле кыйгач канатлы очкычларга утырып, үзебезнең ил буйлап кына түгел, ә турист буларак та, диңгезләр һәм океаннар аша меңәр чакрымлы араларны юлга да санамыйча, бик күп мәмләкәтләргә сәяхәт



Зирекле күл

кылдым. Төркия, Мисыр, Алжир, Һиндстан, Вьетнам, Япония, Куба кебек шактый ерак илләрне; Париж, Рим, Неаполь, Вена, Афина кебек зур-зур шәһәрләрне үз күзләрем белән күрергә насыйп булды. Кыскасы, җиһанның дүрт ягын да аркылыга-буйга иңләп чыктым, дисәм дә, сүзем көфер булмас, дип уйлыйм. Исән чакта йөреп кал, бар дөньяны күреп кал, дигәннәр бит. Әмма чит илләрдә дөньяның җиде могҗизасын күрсәм дә, аларның берсе дә бала чакта үзебезнең Зөя елгасы буйлап тәүге «сәяхәт» иткәндә кичергән тәэсирләргә җитә алмыйлар шул. Ул чагында туган төбәгемнең нәни калкулыклары да миңа әби сөйләгән Каф таулары кебек биек, каршыбыздагы Зирекле күл Кара диңгездәй киң һәм тирән булып тоелган иде.

Ә безнең төбәк — табигатьнең иң бай һәм гүзәл почмакларының берседер, мөгаен. Хәер, бу табигый дә, чөнки һәр кеше үзенең туган җирен шундый итеп күрәсе килә. «Туган ягым — алтын капка» дип тә юкка гына әйтмәгәннәрдер.

Кәшә авылы үзенең киң кырлары, мул печәнле болынлыклары, чәчәкле тугайлары, җиләк-җимешле әрәмәлекләре белән Татарстан җирлегенә уелып керсә дә, чынбарлыкта ул Ульяновск өлкәсендә. Күрәсең, Мәскәү аңлы рәвештә эш иткән. Сәяси күзлектән булса кирәк, нык хуҗалыклы зур татар авылын татар иленнән аерып

алып, рус дөньясына беркеткән. Әмма кәшәлеләр Татарстанга күрше булып кына яшәп ятмыйлар. Ә үзләренең рухи һәм мәдәни кыйбласы итеп алар татар дөньясының мәркәзе Казанны атыйлар. Радио тапшырулары, газета-журналлар гел татарча. Авыл халкы, шул тарафка күз текәп, кайчан да булса яңадан Татарстанга кайтырбыз, дигән өмет белән яши.

Кәшә халкы чыгышы белән Казанга янәшә утырган Югары Ослан төбәгеннән. Ерак бабаларыбыз XVII гасырның урталарында ук бу җирләргә килеп утырган. Үз ихтыярлары белән түгел, әлбәттә. Әмма шуны әйтергә кирәк: матур җирне сайлаганнар. Җидегән чишмәле озын күл буе, шаулап торган нарат урманнары... Россиянең чикләрен дала халыклары һөҗүменнән саклау өчен, Сембер кальгасын салырга кирәк булган. Безнең бабайлар үз атларында нарат бүрәнәләрен нәнә шунда ташыганнар. Ә соңрак исә империя бизгәге йоккан Пётр патша әмере белән төз наратларны шанлы Идел буена кораблар төзергә китергәннәр. Тарих исбат итүенчә, иң авыр хезмәт — лашманчылык эше — тирә-яктагы татар авылларына йөкләтелгән була. Әйе, авыл халкының хезмәте әле дә җиңел түгел. Әмма ерак бабаларыбызның гасырлар томаны аша әнә шул калын бүрәнәләрне арбаларына күтәреп салганда ыңгырашкан авазлары һаман да ишетелә сыман...

Баксаң, йортлары яңа булса да, безнең Кәшә бик борынгы авыл икән! Димәк, без тарихта эзлебез. Бу мәгълүматлар белән мин туган авылыма Сабан туена кайткач таныштым. Туган авылын белмәгән — торган җирен санга сукмаган, диләр. Бу җәһәттән авылыбызда соңгы елларда ачылган музей — үзе бер куанычлы вакыйга.

...Мин авыл музеенда пөхтә итеп тезеп куелган экспонатлар белән таныштым. Музей мөдире Әнвәр абый Насыйров аларның һәркайсы турында тәфсилләп сөйләп бара. Әлеге экспонатларны туплауда ул үзеннән дә зур өлеш керткән. Музейны оештыруда шулай ук Габдерахман абый Вахитов, төрле елларда колхозыбызны җитәкләгән Харис Газизов, агалы-энеле Наил һәм Дамир Гайниевләр ярдәм күрсәткәннәр. Хуҗалыкның элеккеге экономисты — мәрхүм Галимҗан абый Насыйров һәм